КАБИНЕТ МИНИСТРОВ
РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ
МИНИСТРЛАР КАБИНЕТЫ

**ПОСТАНОВЛЕНИЕ** **КАРАР**

2024 ел, 7 декабрь г.Казань № 1114

Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының «Татарстан Республикасы дәүләт органы һәм Россия Федерациясе гражданы арасында белем алып бетергәннән соң алга таба билгеле бер вакыт эчендә Татарстан Республикасы дәүләт граждан хезмәтен үтү йөкләмәсе белән белем алуга шартнамә төзү тәртибе турындагы нигезләмәне раслау хакында» 2011 ел, 8 август, 640 нчы карары белән расланган Татарстан Республикасы дәүләт органы һәм Россия Федерациясе гражданы арасында белем алып бетергәннән соң алга таба билгеле бер вакыт эчендә Татарстан Республикасы дәүләт граждан хезмәтен үтү йөкләмәсе белән белем алуга шартнамә төзү тәртибе турындагы нигезләмәгә үзгәреш кертү хакында

Татарстан Республикасы Министрлар Кабинеты КАРАР БИРӘ:

1. Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының «Татарстан Республикасы дәүләт органы һәм Россия Федерациясе гражданы арасында белем алып бетергәннән соң алга таба билгеле бер вакыт эчендә Татарстан Республикасы дәүләт граждан хезмәтен үтү йөкләмәсе белән белем алуга шартнамә төзү тәртибе турындагы нигезләмәне раслау хакында» 2011 ел, 8 август, 640 нчы карары (Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының 2019 ел, 17 октябрь, 932 нче; 2020 ел, 30 гыйнвар, 49 нчы; 2021 ел, 30 октябрь, 1022 нче; 2023 ел, 31 май, 662 нче, 2024 ел, 9 февраль, 71 нче карарлары белән кертелгән үзгәрешләрне исәпкә алып) белән расланган Татарстан Республикасы дәүләт органы һәм Россия Федерациясе гражданы арасында белем алып бетергәннән соң алга таба билгеле бер вакыт эчендә

Татарстан Республикасы дәүләт граждан хезмәтен үтү йөкләмәсе белән белем алуга шартнамә төзү тәртибе турындагы нигезләмәгә түбәндәге үзгәрешләрне кертергә:

4 пунктның өченче абзацына «һәм Россия Федерациясе Президенты актлары» сүзләрен өстәргә;

7 пунктның «б» пунктчасын түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«б) билгеләнгән форма буенча тутырылган Татарстан Республикасы дәүләт граждан хезмәтенә керү өчен анкетаны;».

Татарстан Республикасы
Премьер-министры А.В.Песошин